ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль, 2022 ел № 13/10

Халык депутатларының Яр Чаллы Шәһәр Советының 2005 елның 17 мартындагы 31/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре гербы һәм флагы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 5, 28 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Халык депутатларының Яр Чаллы Шәһәр Советының 2005 елның 17 мартындагы 31/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре гербы һәм флагы турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/14 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.3.8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2.4 пунктын өстәргә:

«2.4. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, шулай ук физик затлар тарафыннан Яр Чаллы шәһәре гербын куллану тәртибе

2.4.1. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә, гражданнарга Яр Чаллы шәһәре гербын куллану, шулай ук аны ясау әлеге Нигезләмәгә каршы килмәгән очракларда рөхсәт ителә.

Яр Чаллы шәһәре гербын куллану әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Яр Чаллы шәһәре гербын ясау (әзерләү, урнаштыру, предметлар һәм материаллар өслегенә урнаштыру) ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә:

- төсле яисә бер төстәге (төсләрне билгеләү өчен шартлы штрихлар кулланып яисә аннан башка) күләмле яисә график сурәт рәвешендә;

- төрле башкару техникасында;

- билгеләнгән тасвирламасына һәм сурәтенә туры китереп, төсләр (бер төс кулланып ясау очракларыннан тыш) һәм сурәтнең төгәллеген тәэмин итеп.

2.4.3. Яр Чаллы шәһәре гербын куллану түбәндәгеләр белән бәйле булырга тиеш түгел:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән экстремистик эшчәнлеккә каршы тору, вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында, балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында законнарны бозу;

- Яр Чаллы шәһәренә, шулай ук җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына ихтирамсызлык күрсәтү;

- җирле үзидарә органнарына зыян китерү, шулай ук аларның хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен бозу;

- Яр Чаллы шәһәре гербын яман ният белән, мыскыл итеп, шулай ук аны мәсхәрә итеп куллану;

- Яр Чаллы шәһәре гербын кулланучы юридик затның яисә шәхси эшмәкәрнең җирле үзидарә органнарына, аларга буйсынучы оешмаларга каравы турында, шулай ук әлеге органнар һәм оешмалар эшчәнлегенә карата ялгыш фикер тудыру;

- көч куллануны һәм рәхимсезлекне, шулай ук порнографик һәм эротик характердагы чараларны пропагандалаучы товарлар, хезмәтләр, мәгълүмат һәм материалларга урнаштыру;

- алкоголь продукциясен, тәмәке продукциясен һәм тәмәке эшләнмәләрен җитештерүне, сатуны һәм куллануны пропагандалау;

- Яр Чаллы шәһәре гербы белән бергә тискәре мәгънәви, визуаль рәвештә кабул итүгә китерә торган чит ил сүзләрен һәм әйтелмәләрне куллану;

- кешенең һәм гражданның җенесенә, расасына, милләтенә, һөнәренә, социаль категориясенә (хәленә), яшенә, теленә, гражданның теленә, дини символларга, мәдәни мирас объектларына карата сүгенү сүзләрен, оятсыз һәм хурлыклы образлар, шулай ук гражданнарның хокукларын бозучы, милли һәм дини хисләрен рәнҗетүче яисә гражданнарның һәм юридик затларның намусын һәм абруен төшерә, яки эшлекле репутациясен боза торган текстлар һәм сурәтләр белән бергә куллану.

2.4.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә таратыла торган социаль рекламадан тыш, Яр Чаллы шәһәре гербын рекламада куллану, шул исәптән реклама объектының җирле үзидарә органнары тарафыннан яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан хуплануын күрсәтү максатыннан, рөхсәт ителми.

2.4.5. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә аларны әзерләүдән тыш, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мөһерләр, штамплар, бланклар, таныклыклар, грамоталар һәм башка документларда Яр Чаллы гербын куллану һәм аларны сату, куллану рөхсәт ителми.

2.4.6. Яр Чаллы шәһәре гербын юллар (урам-юл челтәре), тротуарлар, җәяүлеләр зоналары, велосипед һәм җәяүлеләр өчен юл өслегендә сурәтләү рөхсәт ителми.

2.4.7.Җәмәгать урыннарында, шулай ук төзекләндерү объектларында, шул исәптән биналар, корылмалар һәм төзелмәләрнең тышкы өслекләрендә кулланыла торган Яр Чаллы шәһәре гербы һәм аның сурәтләре чиста һәм тулы халәттә

булырга тиеш, кирәк булганда, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре гербы элементларын югалтуга яки бозуга китергән тузу яки җимерелү очракларында да, даими рәвештә яңартылырга тиеш.»;

3) 2.4 пунктны 2.5 пункты дип санарга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халыкның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев